Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № VI-3**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 19 декабре

2016 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), күпфатирлы йортта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 маддәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсендәге 1 өлешенең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча 2016 елга социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган (наем өчен түләү), торак урынны карап тоткан өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре, шулай ук гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен түләү күләмен (кушымта № 1).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2015 елның

19 декабрендәге
VI-3 номерлы карары
белән расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы буенча 2016 елга социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган (наем өчен түләү), торак урынны карап тоткан өчен, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре, шулай ук гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре өчен

**түләү күләме**

| | Хезмәт күрсәтүне үлчәү бердәмлеге | Тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр |
| Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 1,54 | 1,62 |
| Биналарны ремонтлау һәм йорт тирәсен төзекләндерү | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 2,13 | 2,23 |
| Йорт эчендәге инженерлык-канализация челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 2,11 | 2,21 |
| Йорт эчендәге үзәк җылыту челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 1,38 | 1,38 |
| Йорт эчендәге электр челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 0,96 | 1,01 |
| Каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү | 1 кешегә | 30,65 | 35,25 |
| Торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. ы | 5,00 | 5,00 |
| Каты көнкүреш калдыкларын чыгару | м. куб. | 82,48 | 119,05 |
| Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | 1 кешегә | 24,26 | 32,24 |